| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>27.03.2024 | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>№ 823 |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 мартындагы 659 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 458 номерлы боерыгы белән расланган, Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының 2023 елның 13 гыйнварындагы «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау хакында» под- 33/23 номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 мартындагы 659 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Административ регламентның 1.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.5.1.1.пунктча өстәргә:

«1.5.1.1. 1998 елның 27 маендагы «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 76-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктына, 2016 елның 3 июлендәге«Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре турында» 226-ФЗ номерлы Федераль Законның 28.1 статьясына ярашлы рәвештә, балалары оешмадан хезмәт күрсәтүне алуга чираттан тыш хокуклы булган ата-аналар (законлы вәкилләр), гаиләләренең яшәү урыны буенча».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru )урнаштырырга.

3. .Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин